ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2020 ел № 38/7

Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон «Аренда килешүләрен, түләүсез файдалану килешүләрен, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү килешүләрен, дәүләт яисә муниципаль милеккә карата хокукларнының күчүен күздә тоткан башка килешүләрне һәм әлеге килешүләрне төзү конкурс формасында сатулар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеген төзү хокукына конкурс яйсә аукөион үткәрү хаеынгңа хакында» Россиянең Монополиягә каршы федераль хезмәтенең 2010 елның 10 февралендәге 67 номерлы боерыгы, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

**КАРАР бирде:**

1. Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2009 елның 22 октябрендәге 43/9, 2010 елның 26 маендагы 50/8, 2011 елның 15 декабрендәге 15/9, 2012 елның 20 апрелендәге 18/8, 2015 елның 15 апрелендәге 39/11, 2018 елның 21 февралендәге 23/10, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/11, 2019 елның 23 маендагы 31/7 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 51.1 пунктын өстәргә:

«51.1. Аренда килешүен төзү хокукының башлангыч (минималь) бәясе бәяләү эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау килешүен төзү хокукын бәяләү турындагы хисап нигезендә билгеләнә.»;

2) 57 пунктны көчен югалткан дип санарга.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев